**9 нчы сыйныф**
**1 нче вариант**

**А1. Сүзнең дөрес язылган вариантын билгеләгез. (2 балл)**
1) кульяулык
2) **кулъяулык**
3) куляулык
4) кул яулык

**А2. Басым дөрес төшкән иҗекне күрсәтегез. (2 балл)**
1) бАшкаручылар
2) башкарУчылар
3) **башкаручылАр**
4)башкАручылар

**А3. Сүзенең иҗекләргә дөрес аерылган вариантын билгеләгез. (2 балл)**
1) **дөнь-я –да-гы**
2) дөнья-да-гы
3) дөнь-я-дагы
4) дө-нья-да-гы

**А4. Сөенә сүзенең синонимын табыгыз. (2 балл)**
1) кайгыра
2) җырлый
3) **куана**
4) бии

**А5. Ялгызлык исемне табыгыз. (2 балл)**
1) **ЗӨЯ**
2) КЕШЕ
3) МАТУРЛЫК
4) КЫҢГЫРАУ

**А6. Хаталы сүзне табыгыз. (3 балл)**
1) янгын
2) **ихтибар**
3) икътисад
4) сырхауханә

**А7. Күпмәгънәле сүзне табыгыз. (3 балл)**

1) керпе
2) аю
3) бүре
4) **тиен**

**А8. *Кыек* сүзенең антонимын табыгыз. (3 балл)**
1) тугъры
2) очлы
3) **туры**
4) борма

**А9. *Чыбык очы* фразеологизмының мәгънәсен табыгыз. (3 балл)**
1) нечкә
2) калын
3) **ерак**
4) бик якын

**А10. Дифтонглары булган сүзләр рәтен билгеләгез. (3 балл)**
1) кышын, тагын
2) **кавын, тавыш**
3) көзән, көзен
4) төгәл, тамыр

**А11. Рәвеш ясагыч кушымчалар кайсы төркемдә? (3 балл)**
1) -лык/-лек, -чан/-чән
2) -ла/-лә, -лы/-ле
3) **-ча/-чә, -дай/-дәй**
4) -лы/-ле, -лай/-ләй

**А12. Билгеләү алмашлыгын күрсәтегез. (3 балл)**
1) минеке
2) кайчан
3) **барлык**
4) кемдер

**А13. Парлы сүзнең икенче компонентын табыгыз. *Урын* – … (3 балл)**
1) урам
2) баш
3) **җир**
4) күлән

**А14. *Озак йөрү* – нинди сүзтезмә? (3 балл)**

1) сыйфатлы фигыль
2) сыйфатлы исем
3) **рәвешле фигыль**
4) рәвешле исем

**А15.** ***Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел*** **(Ш.Галиев) мисалында җөмләнең төрен билгеләгез. (3 балл)**

1) **гади җөмлә**
2) тезмә кушма җөмлә
3) иярчен аныклагыч җөмлә
4) катлаулы кушма җөмлә

**В1. Лексикологиянең торыклы сүз тезмәләрне өйрәнә торган тармагы ... дип атала. (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): ФРАЗЕОЛОГИЯ**

**В2. Дусларым шуны аңламый <...>** ***китап укып, үзеңне баетасың, күңелеңә рәхәтлек аласың*** **(М. Госманов) җөмләсендә <...> тамгасы урынына нинди тыныш билгесе куелырга тиешлеген языгыз. (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән буш аралык калдырмыйча языгыз.**

**Җавап (Ответ): ИКЕНОКТА**

**В3. Экономист сүзенең татарча вариантын языгыз. (4 балл)**

**Җавап сүзне баш хәрефләр белән, баш килештә, берлек санда языгыз.**

**Җавап (Ответ): ИКЪТИСАДЧЫ**

**В4. БИК, ИҢ, ҮТӘ кайсы сүз төркеменә керәләр? Җавап сүзне баш хәрефләр белән, баш килештә, берлек санда языгыз.**

**Җавап (Ответ): КИСӘКЧӘ**

**В5. Антонимнар арасында тәңгәллекләр урнаштырыгыз. (4 балл)**

| | |
|---|---|
| А) шат | 1) гади |
| Ә) мөлаем | 2) искелек |

Б) катлаулы 3) моңсу
В) яңалык 4) кырыс

**Саннар җыелмасын буш ара калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 2413**

**В6. Тезмә фигыльләр барлыкка килерлек итеп, тәңгәллекләр урнаштырыгыз. (4 балл)**

1) кереп А) яту
2) басып Б) бетү
3) яшәп В) тору
4) җыенып Г) чыгу

**Саннар җыелмасын буш ара калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 4312**

**В7. Ж, *т, ө,ү, м, һ, р, я, и* хәрефләреннән сүз төзеп языгыз. Һәр хәреф бер тапкыр гына кулланыла ала.(4 балл)**

**Хәрефләр җыелмасын баш хәрефләр белән буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ):ҖӨМҺҮРИЯТ**

**В8. Хәбәрлекле мөнәсәбәттә торган сүзләр ... барлыкка китерә. (4 балл)**

**Төшеп калган сүзне баш хәрефләрдән, баш килештә, берлек санда языгыз.**

**Җавап (Ответ):** ҖӨМЛӘ

**В9.** ***Минһаҗ тәмам йокысы туеп уянганда, нарат исе аңкып торган өйдә БЕРКЕМ дә юк иде инде.*** **(М. Шәрифуллин) мисалында аерып бирелгән сүз җөмләнең кайсы кисәге була? (4 балл)**

**Җавапны бер сүз белән, баш хәрефләрдән, баш килештә языгыз.**

**Җавап (Ответ): ИЯ**

**В10. Сабыр төбе - …** ***алтын*** **мәкалендә төшеп калган сүзне языгыз. (4 балл)**

**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ):** САРЫ

**В11. Конкурс сүзенең тәрҗемәсен языгыз. (4 балл)**

**Җавап сүзне баш хәрефләр белән, баш килештә, берлек санда языгыз.**

**Җавап (Ответ): БӘЙГЕ**

**B12. Тексттан инверсия рәвешендә язылган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Элек заманда бер бай Мәкәрҗәгә ярминкәгә китә. (2) Була аның өч кызы. (3) Әйтә бу киткән чагында кызларына: «(4)Кызларым, әйтегез: Мәкәрҗәдән кайткан вакытта сезгә нинди бүләк алып кайтыйм?» –(3) ди. (5)Берсе әйтә: «(6) Әти, миңа атлас күлмәк алып кайт», –(5) ди. (7) Уртанчы кызы әйтә: «(8) Миңа сәлисәр күлмәк алып кайт», – (7)ди. (9) Кечкенәсе әйтә: «(10) Миңа күлмәк кирәкми, кеше башы хәтле алма алып кайт», –(9) ди.(*Әкият)*

**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 23**

**B13. Тексттан саннар кулланылган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Элек заманда бер бай Мәкәрҗәгә ярминкәгә китә. (2) Була аның өч кызы. (3) Әйтә бу киткән чагында кызларына: «(4)Кызларым, әйтегез: Мәкәрҗәдән кайткан вакытта сезгә нинди бүләк алып кайтыйм?» –(3) ди. (5)Берсе әйтә: «(6) Әти, миңа атлас күлмәк алып кайт», –(5) ди. (7) Уртанчы кызы әйтә: «(8) Миңа сәлисәр күлмәк алып кайт», – (7)ди. (9) Кечкенәсе әйтә: «(10) Миңа күлмәк кирәкми, кеше башы хәтле алма алып кайт», –(9) ди. *(Әкият)*

**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 12**

**B14. Тексттан алмашлыклар булган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Элек заманда бер бай Мәкәрҗәгә ярминкәгә китә. (2) Була аның өч кызы. (3) Әйтә бу киткән чагында кызларына: «(4)Кызларым, әйтегез: Мәкәрҗәдән кайткан вакытта сезгә нинди бүләк алып кайтыйм?» –(3) ди. (5)Берсе әйтә: «(6) Әти, миңа атлас күлмәк алып кайт», –(5) ди. (7) Уртанчы кызы әйтә: «(8) Миңа сәлисәр күлмәк алып кайт», – (7)ди. (9) Кечкенәсе әйтә: «(10) Миңа күлмәк кирәкми, кеше башы хәтле алма алып кайт», –(9) ди. *(Әкият)*

**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 2346810**

**В15. Тексттан исемләшкән берәмлекләр булган җөмләләрне табыгыз һәм аларның санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Элек заманда бер бай Мәкәрҗәгә ярминкәгә китә. (2) Була аның өч кызы. (3) Әйтә бу киткән чагында кызларына: «(4)Кызларым, әйтегез: Мәкәрҗәдән кайткан вакытта сезгә нинди бүләк алып кайтыйм?» –(3) ди. (5)Берсе әйтә: «(6) Әти, миңа атлас күлмәк алып кайт», –(5) ди. (7) Уртанчы кызы әйтә: «(8) Миңа сәлисәр күлмәк алып кайт», – (7)ди. (9) Кечкенәсе әйтә: «(10) Миңа күлмәк кирәкми, кеше башы хәтле алма алып кайт», –(9) ди. *(Әкият)*
**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 159**

**9 нчы сыйныф**
**2 нче вариант**

**А1. Сүзнең дөрес язылган вариантын билгеләгез. (2 балл)**
1) ашьяулык
2) **ашъяулык**
3) ашяулык
4) аш яулык

**А2. Басым дөрес төшкән иҗекне күрсәтегез. (2 балл)**
1) кУллванучылар
2) кулланУчылар
3) кулланучы**лАр**
4) куллАнучылар

**А3. Сүзенең иҗекләргә дөрес аерылган вариантын билгеләгез. (2 балл)**
1) **ә-ки-ят-тә-ге**
2) әки-ят-тәге
3) ә-ки-яттә-ге
4) әки-яттә-ге

**А4. Кайгыра сүзенең синонимын табыгыз. (2 балл)**
1) шатлана
2) елый
3) **борчыла**

4) улый

**А5. Ялгызлык исемне табыгыз. (2 балл)**

1) **БИЕКТАУ**

2) КУНАК

3) КАЗАХ

4) ЧАЛГЫ

**А6. Хаталы сүзне табыгыз. (3 балл)**

1) мөһер
2) **мөһәррир**
3) җыелыш
4) мисал

**А7. Күпмәгънәле сүзне табыгыз. (3 балл)**

1) курчак
2) велосипед
3) быргы
4) **туп**

**А8. *Сатлыкҗан* сүзенең антонимын табыгыз. (3 балл)**

1) **тугъры**
2) гади
3) туры
4) борчулы

**А9. *Тишек авыз* фразеологизмының мәгънәсен табыгыз. (3 балл)**

1) күп сөйләүче
2) гайбәтче
3) **сер татмаучы**
4) ашый алмаучы

**А10. Дифтонглары булган сүзләр рәтен билгеләгез. (3 балл)**

1) арба, болын
2) **ялгыз, ерак**
3) көрәк, беләк
4) камыр, чкапкач

**А11. <u>Сыйфат</u> ясагыч кушымчалар кайсы төркемдә? (3 балл)**

1) -лык/-лек, -дай/-дәй
2) -ла/-лә, -ды/-де

3) **–лы/ле,** -чан/-чән
4) -гы/-ге, -чы/-че

**А12. Билгеләү алмашлыгын күрсәтегез. (3 балл)**
1) без
2) кемнеке
3) **үзем**
4) кайда

**А13. Парлы сүзнең икенче компонентын табыгыз. *Күрше* – ... (3 балл)**
1) урам
2) туган
3) дус
4) **күлән**

**А14. *Тиз кайту* – нинди сүзтезмә? (3 балл)**
1) сыйфатлы фигыль
2) сыйфатлы исем
3) **рәвешле фигыль**
4) рәвешле исем

**А15. *Күп укысаң, күп белерсең* (М.Колый) мисалында җөмләнең төрен билгеләгез. (3 балл)**
1) **гади җөмлә**
2) тезмә кушма җөмлә
3) иярчен аныклагыч җөмлә
4) катлаулы кушма җөмлә

**В1. Тел белеменең сүз төркемнәрен өйрәнә торган тармагы ... дип атала. (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): МОРФОЛОГИЯ**

**В2. Безгә шунысы билгеле булды <...> *ул алай тиз генә бирешә торганнардан түгел* (М.Хәбибуллин) җөмләсендә <...> тамгасы урынына нинди тыныш билгесе куелырга тиешлеген языгыз. (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән буш аралык калдырмыйча языгыз.**

**Җавап (Ответ): ИКЕНОКТА**

**В3. БУХГАЛТЕР сүзенең татарча вариантын языгыз. (4 балл)**

**Җавап сүзне баш хәрефләр белән, баш килештә, берлек санда языгыз.**

**Җавап (Ответ):** ХИСАПЧЫ

**В4. ГЫНА, ИЧ, СОҢ кайсы сүз төркеменә керәләр?** **Җавап сүзне баш хәрефләр белән, баш килештә, берлек санда языгыз.**

**Җавап (Ответ): КИСӘКЧӘ**

**В5. Антонимнар арасында тәңгәллекләр урнаштырыгыз. (4 балл)**

| | |
|---|---|
| А) шук | 1) яңа |
| Ә) кыбырсык | 2) җитди |
| Б) иске | 3) шатлык |
| В) борчу | 4) тыныч |

**Саннар җыелмасын буш ара калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 2413**

**В6. Тезмә фигыльләр барлыкка килерлек итеп, тәңгәллекләр урнаштырыгыз. (4 балл)**

| | |
|---|---|
| 1) укып | А) тору |
| 2) кайтып | Б) китү |
| 3) ятып | В) килү |
| 4) кузгалып | Г) утыру |

**Саннар җыелмасын буш ара калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 4312**

**В7. К, ы, л, а, у, ж, х хәрефләреннән сүз төзеп языгыз. Һәр хәреф бер тапкыр гына кулланыла ала.(4 балл)**
**Хәрефләр җыелмасын баш хәрефләр белән буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): ХУҖАЛЫК**

**В8. Ияртүле мөнәсәбәттә торган сүзләр ... барлыкка китерә. (4 балл)**
**Төшеп калган сүзне баш хәрефләрдән, баш килештә, берлек санда языгыз.**

**Җавап (Ответ):** СҮЗТЕЗМӘ

**В9.** ***Минһаҗ тәмам йокысы туеп уянганда, НАРАТ ИСЕ аңкып торган өйдә беркем дә юк иде инде.*** **(М. Шәрифуллин) мисалында аерып бирелгән сүз җөмләнең кайсы кисәге була? (4 балл)**
**Җавапны бер сүз белән, баш хәрефләрдән, баш килештә языгыз.**

**Җавап (Ответ): ИЯ**

**В10.** ***Китап - ... чишмәсе*** **мәкалендә төшеп калган сүзне языгыз. (4 балл)**

**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ):** БЕЛЕМ

**В11. КРЕСЛО сүзенең татарчага тәрҗемәсен языгыз. (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән, баш килештә, берлек санда языгыз.**

**Җавап (Ответ):** КӘНӘФИ

**В12. Тексттан инверсия рәвешендә язылган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Китте бу Мәкәрҗәгә. (2) Сату итте, алдап-йолдап бик күп табыш итте. (3)Кайтыр вакыт җиткәч, беренче кызына атлас күлмәк алды, икенчесенә сәлисәр күлмәк алды. (4) Аннары эзләргә кереште кечкенә кызына алма. (5) Эзли-эзли, кеше башы хәтле алма таба алмый. (6)Кечкенә кызын кайгырта, «бу нәүмиз була инде», ди, ничек тә булса шундый алма табарга уйлый.
(7)Мәкәрҗә вакыты үтә. (8) Шәһәрдәгеләр бар да кайтып китәләр. (9) Бу бер айгыр ала да, атланып, шул алманы эзләргә китә. (10) Очраса, ничек булса да алманы аласы инде. (*Әкият)*
**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 14**

**В13. Тексттан саннар кулланылган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Китте бу Мәкәрҗәгә. (2) Сату итте, алдап-йолдап бик күп табыш итте. (3)Кайтыр вакыт җиткәч, беренче кызына атлас күлмәк алды, икенчесенә сәлисәр күлмәк алды. (4) Аннары эзләргә кереште кечкенә кызына алма. (5) Эзли-эзли, кеше башы хәтле алма таба алмый. (6)Кечкенә кызын кайгырта, «бу нәүмиз була инде», ди, ничек тә булса шундый алма табарга уйлый.

(7)Мәкәрҗә вакыты үтә. (8) Шәһәрдәгеләр бар да кайтып китәләр. (9) Бу бер айгыр ала да, атланып, шул алманы эзләргә китә. (10) Очраса, ничек булса да алманы аласы инде. (*Әкият)*

**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 39**

**B14. Тексттан алмашлыклар булган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Китте бу Мәкәрҗәгә. (2) Сату итте, алдап-йолдап бик күп табыш итте. (3)Кайтыр вакыт җиткәч, беренче кызына атлас күлмәк алды, икенчесенә сәлисәр күлмәк алды. (4) Аннары эзләргә кереште кечкенә кызына алма. (5) Эзли-эзли, кеше башы хәтле алма таба алмый. (6)Кечкенә кызын кайгырта, «бу нәүмиз була инде», ди, ничек тә булса шундый алма табарга уйлый.
(7)Мәкәрҗә вакыты үтә. (8) Шәһәрдәгеләр бар да кайтып китәләр. (9) Бу бер айгыр ала да, атланып, шул алманы эзләргә китә. (10) Очраса, ничек булса да алманы аласы инде. (*Әкият)*

**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 268910**

**B15. Тексттан исемләшкән берәмлекләр булган җөмләләрне табыгыз һәм аларның санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Китте бу Мәкәрҗәгә. (2) Сату итте, алдап-йолдап бик күп табыш итте. (3)Кайтыр вакыт җиткәч, беренче кызына атлас күлмәк алды, икенчесенә сәлисәр күлмәк алды. (4) Аннары эзләргә кереште кечкенә кызына алма. (5) Эзли-эзли, кеше башы хәтле алма таба алмый. (6)Кечкенә кызын кайгырта, «бу нәүмиз була инде», ди, ничек тә булса шундый алма табарга уйлый.
(7)Мәкәрҗә вакыты үтә. (8) Шәһәрдәгеләр бар да кайтып китәләр. (9) Бу бер айгыр ала да, атланып, шул алманы эзләргә китә. (10) Очраса, ничек булса да алманы аласы инде. (*Әкият)*

**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 38**